**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә**

2019 елның 08 июне

1. Гавами тыңлаулар уздыру нигезләре.

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» проекты буенча гавами тыңлаулар (алга таба проект) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1., 30-32 статьялары, «РФда җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Сеҗе авыл җирлеге башлыгы карары нигезендә үткәрелде

2. Гавами тыңлауларда тәкъдим ителгән проект турында гомуми мәгълүмат.

Эшләү территориясе: Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге.

Заказ бирүче: Арча муниципаль районы башкарма комитеты.

3. Гавами тыңлаулар үткәрү турында хәбәр итү рәвеше:

Проект материаллары Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылды.

4. Гавами тыңлауларда катнашучылар:

- авыл җирлегендә яшәүчеләр.

5. Проект материаллары экспозициясен уздыру турында белешмәләр.

Проектның демонстрацион материаллары экспозицияләре авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслары буенча урнаштырылды: Сеҗе, Мәктәп ур., 15, Курса Почмак Мәктәп ур. 1,Сикертән,Үзәк урам,14.

Проектның төп материаллары авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми хокукый порталда урнаштырылды.

6. Гавами тыңлаулар уздыру турында белешмәләр.

Гавами тыңлаулар башлык карары белән расланган графигк нигезендә үткәрелде.

Тыңлауларны уздыру срогы -07 июнь, 2019ел.

Үткәрү урыны: Курса Почмак авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт, админ.бина.

7. Проект буенча искәрмәләр, тәкъдимнәр- гавами тыңлаулар уздырганчы язма кисәтүләр һәм тәкъдимнәр килмәде; - гавами тыңлаулар үткәрү барышында кермәде.

8. Проект буенча гавами тыңлаулар беркетмәләре турында белешмәләр: 2019 елның 07 июнендәге 1 номерлы гавами тыңлаулар беркетмәсе.

9. Нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү процедурасы үтәлде һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары таләпләренә туры килә, шуңа бәйле рәвештә Сеҗе авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар узды дип саный.

2.Әлеге нәтиҗә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында җирлек бүлегендә районның рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында каралырга тиеш.

Гавами тыңлауларны уздыру өчен җаваплы — Г.М.Гибадуллина.

Секретарь — Р.Х.Мухамадиев